РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.12.2024

КАРАР
№ 1135-п

2025 елда халыкка күрсәтелә торган торак
хезмәтләренә тарифлар турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 03 апрелендәге 290 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап торткан өчен түләү күләмен, торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап торткан өчен түләү күләмен, Татарстан Республикасының Саба муниципаль районы буенча 2025 елга халык өчен күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап торткан өчен түләү күләмен расларга һәм гамәлгә кертергә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – икътисад бүлеге башлыгы М.М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М. Р. Ишниязов

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының<br>
2024 елның 28 декабрендәге 1135-п<br>
номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**2025 елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы буенча халык өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен халык өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме**

| т/б № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2025 елның 1 гыйнварыннан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум. | 2025 елның 1 июленнән хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 2,76 | 3,07 |
| 2 | Торак бинаны агымдагы ремонтлау | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 3,02 | 3,36 |
| 3 | Ишегалдын тоту (җәйге чорда үлән һәм чүп үләннәрен чабу) | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 0,46 | 0,51 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту: | | | |
| | суүткәргеч-канализация челтәрләре | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 2,22 | 2,47 |
| | суүткәргеч челтәрләре | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 1,98 | 2,20 |
| | үзәкләштерелгән җылыту челтәрләре | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 2,57 | 2,85 |
| | электр белән тәэмин итү челтәрләре | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 1,25 | 1,38 |
| | вентиляция каналларын тикшерү (карау) | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 0,43 | 0,24 |
| | төтенлекләр системаларын тикшерү (карау) | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | | 0,24 |
| | домофон хезмәте күрсәтү | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 0,41 | 0,45 |
| 5 | Фасад газүткәргечләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 0,41 | 0,45 |
| 6 | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару өчен тариф ставкасы | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 14,73 | 16,35 |
| 7 | Торак урынны наемга алган өчен түләүнең иң чик ставкасы | бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. | 31,53 | 33,01 |